ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**22.03.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 582**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 10 апрелендәге 743 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2020 елның 26 ноябрендәге 7036 номерлы, 2020 елның 24 декабрендәге 7483 номерлы, 2021 елның 15 гыйнварындагы 7507 номерлы, 2021 елның 26 гыйнварындагы ң 7522 номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 11 ноябрендәге «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга опекун (попечитель) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында (түләүле яисә түләүсез шартларда), яисә опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү хакында» 1148/20 номерлы, 2020 елның 05 декабрендәге «Банкта яисә башка кредит оешмасында счетта (кертемдә) торучы балигъ булмаган затның счетын ябуга, төшереп калдыруга, күчерүгә, тотуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 1158/20 номерлы карары, 2020 елның 11 декабрендәге «Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка (кызлыкка) алу мөмкинлеге һәм уллыкка (кызлыкка) алуга кандидат буларак исәпкә кую турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» под-1326/20 номерлы, 2020 елның 09 декабрендәге «Балигъ булмаганнарның күчмә мөлкәтен тартып алу буенча алыш-бирешләр кылуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 1305/20 номерлы боерыклары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 10 апрелендәге 743 номерлы карарының 1 пунктының 1.12, 1.13, 1.15, 1.19 пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип таныргa.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигы Р.З. Хаҗиевка әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җитәкчесе урынбасары - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе начальнигына йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Ганиев